ГЛАВА
КУКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422669 с.Кукеево
ул. Новая, дом 5

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК-БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

422669, Күки авылы
Яңа ур. 5 йорт

Тел.: (84361) 30581, факс: (84361) 30581, эл.адрес: Kuk.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

от 11.11.2025 года Күки авылы №1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең Күки авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2025 елның 20 мартындагы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 маддәсе, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең Күки авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2025 елның 21 ноябрендә 13сәг. 00 минутка билгеләргә.
2. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү территориаль билге буенча гамәлгә ашырылуын расларга.
3. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең Күки авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, сәләтсез гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан кала ) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

1. Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
2. Су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны

чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

3. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
4. Торак пунктларның башка территорияләрен төзекләндерү;
5. Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

4. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Күки авылы, Яңа урамы, 5 йорт, һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда.

5. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге башлыгы А.М.Бәдретдинов